СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.04.2021 ел № 8-43

с. Шеланга

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең 2020нче ел өчен бюджеты үтәлеше турында отчетны раслау турында

Шилангы авыл җирлеге Башлыгы В. В. Майоровның 2020нче елга Шилангы авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисабын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң,

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Шилангы авыл җирлегенең 2020нче елгы бюджеты үтәлеше турында отчет расларга (1нче кушымта).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советының бюджет-финанс һәм икътисади мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров

Югары Ослан муниципаль
районы Шилангы авыл
җирлеге Советының
2021нче елның 17нче
апреленнән
8-43нче номерлы крарына
1нче кушымта

Шилангы авыл җирлегенең бюджеты, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, 12 миллион 308 мең сумнан артык күләмдә расланды, шулардан:
- үз керемнәре 7 миллион 895 мең сум тәшкил итә, бу 64% якын .
- 2019нчы елның 1нче апреленә җыелган үзара салым акчалары, шул исәптән Республикадан алынган дотацияләр - 1 миллион 940 мең сум, бу 15,7% тәшкил итә.
– 2 миллион 473 мең сум-дотация, бу 20 %.

Авыл җирлеге бюджетының керем өлеше түбәндәге салымнар хисабына формалашты:

- физик затлар керемен\u04d9 салым-112 % ка үтәлгән, бу 367 мең сум тәшкил итә;
- физик затлар милкенә салым 96 % үтәлгән, бу-339 мең сум;
- җир салымы 108 % үтәлгән, бу-6 469 мең сум;
Шул исәптән физик затлардан -97 %. бу 1 035 мең сум тәшкил итә
Юридик затлар-110 %, бу 5 434 мең сум тәшкил итә.
Үз керемнәрнең гомуми күләме 112 % тәшкил итә.

Милек буенча үтәлмәгән салымнар буенча-4%, физик затлардан җир салымы 3%. Әлеге ике салым буенча недоимка 44 мең сум тәшкил иткән. Безнең тарафтан түбәндәге эш башкарылды: бурычлылар белән әңгәмә үткәрелде һәм әҗәтләрне түләү турында бурычлы кешеләргә белдерү юлланды.

Салымнар буенча арттырып үтәлү проценты Авыл җирлеге Башкарма комитеты, районның Финанс-бюджет палатасы белгечләре тарафыннан узган елларда салым түләү буенча бурычлылар белән алып барылган эш белән бәйле. Шулай да салымнар түләү буенча бурычлар бар һәм алар арта.

Бюджетның чыгым өлеше 10 миллион 529 мең сум күләмендә расланган, 88,4% үтәлгән, планлаштырылган барлык чыгымнар да үтәлгән.

Җирлек бюджеты чыгымнарының төп өлеше-төзекләндерү, бу эшләргә 601,0 мең сум акча бүлеп бирелгән. Слайдта күренгәнчә, төп чыгымнар-юлларны кардан чистарту һәм чүп-чарны бетерү, төяү эшләре. Елдан-ел чүп-чар арта бара, гәрчә ишегаллары, урамнар һәм торак пунктларның «күмелгән урыннары» чистартыла башласа да, иске чүп-чар күмелә.

Электр энергиясе өчен миллион ярымнан артык акча, 674,6 мең сум (узган ел 498,8 мең сум), авыл мәдәният йортының электр энергиясе (нигездә җылылык) 200 мең сум акча тотылган. Шуларның 686 сумы - урам утлары өчен (узган ел 660 мең сум). Чыгымнар узган ел белән чагыштырганда артты, әмма урам утлары фонарьлары саны да 24кә артты, урам утының эш режимы, Шилангыда ут системасын кертү һәм сүндерү вакыт буенча җайга салына, экономияләү һәм энергияне сак тоту максатыннан үткәрелгән чара икәнен авыл халкы күреп алды.

Ел башына авыл җирлегендә барлыгы 207 данә фонарь бар, 1 фонарьга чыгымнар айга 229 сум тәшкил итә ( чагыштыру өчен, узган ел бу сан айга 302 сум иде. )

Калган торак пунктларда урамнарны яктырту счетчик буенча эшли, 2020нче елда электр тапшыру линияләренә технологик тоташтыру өчен 13,5 мең сум түләнде. Өстәмә 3 исәпкә алу щиты куелды.

План буенча 2021нче елга авыл җирлеге бюджетының гомуми кереме 6,9 млн. сум күләмендә расланган, шуның үз керемнәре 6,7 млн.сум -(97%), дотацияләр -140 мең сум (3%).

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров